РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Татарско-Шуганского сельского
поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Советская, д. 41в, Азнакаевский район,
с.Татарский Шуган, 423327,
тел./факс (885592)36-1-41
E-mail: Tshug.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Татар Шуганы авыл җирлеге
башкарма комитеты

Совет ур., 41в йорт, Азнакай районы, Татар
Шуганы авылы, 423327
тел./факс (885592)36-1-41
E-mail: Tshug.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«20» февраль 2024 ел.** **№ 4**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 31 октябрендәге 13 номерлы «Татарстан Республикасы Татар Шуганы авыл җирлеге территориясендә муниципаль һәм дәүләт милкендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү рекреацион зоналарын булдыру һәм куллану кагыйдәләре турында» карарының үз көчен югалтуын тану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 27 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуганы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 31 октябрендәге 13 номерлы «Татарстан Республикасы Татар Шуганы авыл җирлеге территориясендә муниципаль һәм дәүләт милкендәге гомуми файдаланудагы су объектларының су саклау зонасында ял итү рекреацион зоналарын булдыру һәм куллану кагыйдәләре турында» карарының үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык М.Ш.Хәертдинов